**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**2026 елда «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенә грант ярдәме турында**

Татарстан Республикасында математика, табигать фәннәре һәм технологияләр юнәлешләрендәге предметлар тирәнтен өйрәнелә торган гомуми белем бирү мәгариф программаларын, шулай ук мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программаларын һәм аутистлык спектры тайпылышлары булган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны махсус шартларда укыту, тәрбияләү һәм үстерү өчен өстәмә гомумүсеш программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына ярдәм итүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруны дәвам иттерү максатларында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^5$ статьясы 2 пункты 1 пунктчасы нигезендә **карар бирәм:**

1. 2026 елда «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесен түбәндәге грантларны алучы дип билгеләргә:

«Татарстан Республикасында математика, табигать фәннәре һәм технологияләр юнәлешләрендәге предметлар тирәнтен өйрәнелә торган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү мәгариф программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына ярдәм күрсәтү»;

«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, структурасына мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программалары, җайлаштырылган мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программалары һәм аутистлык спектры тайпылышлары булган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны махсус шартларда укыту, тәрбияләү һәм үстерү өчен өстәмә гомумүсеш программалары буенча мәгариф эшчәнлеге алып бару төп эшчәнлек төре булып торган бүлекчә кергән югары белем бирү мәгариф оешмасына ярдәм күрсәтү».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә;

әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән грантларның максатчан файдаланылуын контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

әлеге Указны гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2026 ел, 23 июнь
№ 503